# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында" 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9-10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге органнарының, шулай ук халыкка социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкны эш белән тәэмин итү учреждениеләренең наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча вәкаләтләре**

1. Башкарма хакимиятнең хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендәге органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча программалар эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклауны һәм исәпкә алуны оештыру;

3) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар белән наркоманияне профилактикалау буенча үз компетенциясе кысаларында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

4) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкны эш белән тәэмин итү учреждениеләре вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклау һәм исәпкә алу;

2) социаль куркыныч хәлдәге һәм башка авыр тормыш вәзгыятендәге гражданнарга һәм балаларга законнар нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү;

3) сәламәт яшәү рәвешен алып баруны нигезләүгә, гаилә мөнәсәбәтләрен торгызуга юнәлдерелгән профилактика һәм реабилитация программаларын гамәлгә ашыру;

4) психоактив матдәләрне чиктән тыш күп кулланудан дәвалану курсын үткән затларга эшчәнлек төрен һәм һөнәр сайлауда, аларны эшкә урнаштыруда, һөнәри әзерләүдә ярдәм итү;

5) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.";

2) 17 статьяда:

а) 2 өлештә "Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан" сүзләреннән соң "һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклардан" сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә "җирле бюджет акчаларыннан" сүзләреннән соң "һәм закон белән тыелмаган башка чыганаклардан" сүзләрен өстәргә;

3) 26 статьяның 2 өлешендә "медик-социаль реабилитацияләүдә катнашалар" сүзләрен "социаль реабилитацияләүдә катнашалар" сүзләренә, "комплексын эшлиләр һәм гамәлгә ашыралар" сүзләрен "комплексын эшлиләр һәм аны гамәлгә ашыруда катнашалар" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 22 ноябре
№ 81-ТРЗ